# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 ноября 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 27 (часть I), № 55 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 36 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 17 (часть I), № 24 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 73 (часть I), № 81 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 8 части 1 статьи 18 слова «федеральными законами» заменить словами «Федеральным законом «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации»;

2) статью 46 признать утратившей силу;

3) дополнить главой $6^1$ следующего содержания:

«Глава $6^1$. **Международные и внешнеэкономические связи органов местного самоуправления**

Статья 49[1]. **Порядок согласования осуществления органами местного самоуправления международных и внешнеэкономических связей**

1. Международные и внешнеэкономические связи осуществляются органами местного самоуправления в целях решения вопросов местного значения по согласованию с Кабинетом Министров Республики Татарстан в порядке, установленном настоящей статьей.

2. Органы местного самоуправления осуществляют международные и внешнеэкономические связи в следующих формах:

1) проведение встреч, консультаций и иных мероприятий в сфере международных и внешнеэкономических связей с представителями государственно-территориальных, административно-территориальных и муниципальных образований иностранных государств;

2) заключение соглашений об осуществлении международных и внешнеэкономических связей (далее также в настоящей главе – соглашение) с органами местного самоуправления иностранных государств;

3) участие в деятельности международных организаций в сфере межмуниципального сотрудничества в рамках полномочий органов, созданных специально для этой цели;

4) участие в разработке и реализации проектов международных программ межмуниципального сотрудничества;

5) в иных формах, не противоречащих законодательству.

3. Органы местного самоуправления не позднее 45 дней до предполагаемой даты начала осуществления международных и внешнеэкономических связей направляют посредством единой межведомственной системы электронного документооборота Республики Татарстан в Кабинет Министров Республики Татарстан обращение о согласовании осуществления международных и внешнеэкономических связей.

4. Обращение, предусмотренное частью 3 настоящей статьи, должно содержать:

1) сведения о форме и сроках осуществления международных и внешнеэкономических связей;

2) сведения о государственно-территориальных, административно-территориальных и муниципальных образованиях иностранных государств, с представителями которых планируется осуществление международных и внешнеэкономических связей;

3) цели осуществления международных и внешнеэкономических связей с указанием конкретного вопроса местного значения, на решение которого направлено их осуществление, описание ожидаемого результата осуществления международных и внешнеэкономических связей;

4) расчет затрат на осуществление международных и внешнеэкономических связей, содержащий в том числе сведения о средствах местного бюджета, планируемых к направлению на осуществление международных и внешнеэкономических связей.

5. В случае планируемого осуществления международных и внешнеэкономических связей в форме заключения соглашения к обращению, предусмотренному частью 3 настоящей статьи, прилагаются проект указанного соглашения и документы, подтверждающие полномочия лиц на его подписание.

6. Порядок и сроки рассмотрения Кабинетом Министров Республики Татарстан обращения органа местного самоуправления о согласовании осуществления международных и внешнеэкономических связей устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

7. Результаты рассмотрения Кабинетом Министров Республики Татарстан обращения органа местного самоуправления о согласовании осуществления международных и внешнеэкономических связей доводятся до сведения органа местного самоуправления, направившего указанное обращение, не позднее 15 дней до предполагаемой даты начала осуществления международных и внешнеэкономических связей посредством единой межведомственной системы электронного документооборота Республики Татарстан.

Статья $49^2$. **Порядок регистрации соглашений об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органов местного самоуправления**

1. Соглашение об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления не позднее пяти дней со дня подписания соглашения представляется органом местного самоуправления в республиканский орган исполнительной власти, уполномоченный Кабинетом Министров Республики Татарстан (далее в настоящей статье – уполномоченный орган), для регистрации.

2. Одновременно с соглашением об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления в уполномоченный орган представляются заверенные главой муниципального образования копии:

1) подписанного соглашения;

2) проекта соглашения, согласованного Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии со статьей $49^1$ настоящего Закона.

3. Уполномоченный орган рассматривает представленное соглашение об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления и не позднее трех дней со дня представления соглашения принимает решение о его регистрации либо об отказе в его регистрации.

4. Основанием для принятия решения о регистрации соглашения об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления является соответствие такого соглашения проекту соглашения, согласованному Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии со статьей $49^1$ настоящего Закона.

5. Основанием для принятия решения об отказе в регистрации соглашения об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления является несоответствие такого соглашения проекту соглашения, согласованному Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии со статьей $49^1$ настоящего Закона.

6. В случае принятия решения о регистрации соглашения об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления уполномоченный орган присваивает регистрационный номер такому соглашению и направляет его органу местного самоуправления, представившему соглашение. Копия указанного соглашения с присвоенным ему регистрационным номером подлежит хранению в уполномоченном органе.

7. В случае принятия решения об отказе в регистрации соглашения об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органа местного самоуправления уполномоченный орган возвращает такое соглашение и материалы к нему органу местного самоуправления, представившему соглашение, с указанием причин отказа в регистрации соглашения.

8. Регистрация уполномоченным органом соглашений об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органов местного самоуправления является обязательным условием вступления таких соглашений в силу.

9. Подписанные соглашения об осуществлении международных и внешнеэкономических связей органов местного самоуправления подлежат опубликованию (обнародованию) в порядке, предусмотренном для опубликования (обнародования) муниципальных правовых актов.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
09 декабря 2023 года
№ 122-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктында «федераль законнар» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 46 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ бүлек өстәргә:
«$6^1$ бүлек. **Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлары**

## $49^1$ статья. Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү тәртибе

1. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыра:

1) чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре вәкилләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар өлкәсендә очрашулар, консультацияләр һәм башка чаралар уздыру;

2) чит дәүләтләрнең җирле үзидарә органнары белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турындагы килешүләр (алга таба шулай ук әлеге бүлектә – килешү) төзү;

3) муниципальара хезмәттәшлек өлкәсендә халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашу максатында махсус төзелгән органнар вәкаләтләре кысаларында мондый эшчәнлектә катнашу;

4) муниципальара хезмәттәшлекнең халыкара программалары проектларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

5) законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә.

3. Җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруның рәвеше һәм сроклары турында белешмәләр;

2) вәкилләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре хакында белешмәләр;

3) җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләне күрсәтеп, мондый мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру максатлары, халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен тасвирлау;

4) халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру чыгымнарының исәп-хисабы, аңа шул исәптән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру өчен җибәрүгә планлаштырыла торган җирле бюджет акчалары турындагы белешмәләр дә керә.

5. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны килешү төзү рәвешендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, әлеге статьяның 3 өлешендә каралган

мөрәҗәгатькә әлеге килешүнең проекты һәм затларның аңа имза салу вәкаләтләрен раслаучы документлар кушып бирелә.

6. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау тәртибен һәм срокларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

7. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.

### $49^2$ статья. **Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында килешүләрне теркәү тәртибе**

1. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү аңа имза салынган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән республика башкарма хакимият органына (алга таба әлеге статьяда – вәкаләтле орган) теркәү өчен тапшырыла.

2. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү белән берьюлы вәкаләтле органга муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан таныкланган түбәндәгеләрнең күчермәләре тапшырыла:

1) имзаланган килешүнең;

2) әлеге Законның $49^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектының.

3. Вәкаләтле орган җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында тапшырылган килешүне карый һәм килешү тапшырылган көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча аны теркәү хакында йә аны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәү хакында карар кабул итү өчен нигез булып мондый килешүнең әлеге Законның $49^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектына туры килүе тора.

5. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәүдән баш тарту хакында карар кабул итү өчен нигез булып мондый килешүнең әлеге Законның $49^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектына туры килмәве тора.

6. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәү хакында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган мондый килешүгә теркәү номеры бирә һәм аны килешүне тапшырган җирле үзидарә органына җибәрә. Теркәү номеры бирелгән әлеге килешүнең күчермәсе вәкаләтле органда сакланырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган, килешүне теркәүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мондый килешүне һәм аңа материалларны килешүне тапшырган җирле үзидарә органына кире кайтара.

8. Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне вәкаләтле орган тарафыннан теркәү мондый килешүләрнең үз көченә керүенең мәҗбүри шарты булып тора.

9. Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында имзаланган килешүләр муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) өчен каралган тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 122-ТРЗ